ULUSLARARASI TÜRK LEHÇE ARAŞTIRMALARI DERGİSİ (TÜRKLAD), 7. CİLT, 1. SAYI, 2023, 127 - 136. s., TÜRKİYE

https://doi.org/10.30563/turklad.1260265

İntihal / *Plagiarism*

*This article was checked by* turnitin programında bu makale taranmıştır

Makale Bilgisi / *Article information*

| | |
|---|---|
| Makale Türü / *Article types* | : Araştırma Makalesi / *Research article* |
| Geliş Tarihi / *Received date* | : 04.03.2023 |
| Kabul Tarihi / *Accepted date* | : 30.05.2023 |
| Yayın Tarihi / *Date published* | : 20.06.2023 |

Atıf / *Citation*

Узун, М. (2023). Гаяз Исхакыйның "Бай Угылы" Романында Дин һәм Милләт Төшенчәләре. *Uluslararası Türk Lehçe Araştırmaları Dergisi / International Journal of Turkic Dialects (TÜRKLAD)*. 7. Cilt, 1. Sayı, 127-136.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ "БАЙ УГЫЛЫ" РОМАНЫНДА ДИН ҺӘМ МИЛЛӘТ ТӨШЕНЧӘЛӘРЕ

*The religion and nationality phenomena in Ayaz Ishakî's novel "Bay Uğılı"*

**МУРАТ УЗУН** [1]

## Öz

Татар әдәбиятының күренекле шәхесләреннән берсе, татар әдәби теле үсешенә үзеннән зур өлеш керткән Гаяз Исхакый 1878 елның 23 февралендә Казан губерниясе Чистай өязенең Яуширмә авылында дөньяга килә. Башта әтисендә, соңыннан Чистайда һәм Казанның Күл буе мәдрәсәсендә белем ала. Татар укытучылар гимназиясендә укуын дәвам итеп, биредә рус телен үзләштерә. Монда укыганда ул каләм тибрәтә башлый. Гомерен халкына, милләткә хезмәткә багышлаган Исхакый, газета-журналлар нәшер итә, күпсанлы пьесалар, хикәяләр, романнар иҗат итеп калдыра. 1954 елның 22 июлендә Әнкарада вафат була.

Нәшир, язучы, мөгаллим, сәясәтче Исхакый, бер аралар социализм тарафлы булса да, сәяси вәзгыятьләр өметләрен акламагач, фикерен үзгәртә. Яшьлек елларында укыган "Тәрҗеман" газетасы Исхакыйда миллиятче һәм хөрриятче фикерләренең уртага чыгуына һәм ныгуына сәбәпче була.

"Бай угылы" әсәрендә Исхакый үз чорының бай гаиләләрен һәм аларның дөньяга карашын/мөнәсәбәтен чагылдырган. Романдагы вакыйгалар бай, ләкин надан бер гаиләнең бердәнбер баласы булган Кәрим тирәсендә бара. Гаиләсенең наданлыгы, тәрбияче итеп алынган Фәхринең хәйләкәрлеге, иске карашлы кешеләрнең динне бер куллану чарасына әйләндерүләре һәм татар милләтенең түбән дәрәҗәдә булуы әсәрдә каләмгә алынган хосусларны тәшкил итә. Романда Исхакый милләтенең юкка чыкмавы өчен кирәк булган иң мөһим мәсьәләләрне күтәреп чыга.

Бу мәкаләдә Исхакыйның "Бай угылы" романында дин һәм милләт төшенчәләре каралачак.

**Anahtar Kelimeler:** Гаяз Исхакый, Роман, Дин, Милләт, Милли Кемлек

[1] Др., Измит Белем һәм сәнгать үзәге. Кожаэли/Төркия. el-mek: tfmuratuzun@gmail.com
ORCİD ID: https://orcid.org/0000-0002-6285-2271

**Abstract**

Ayaz Ishaki is one of the most important founding figures of contemporary Tatar language and literature. Ishaki was born on February 23, 1878 in the village of Yawshirme in the Chistay province of Kazan. He was educated firstly by his father, then he continued his education in Chistay and at Madrasah of Kyul Buyi in the Kazan. He studied at Tatar Teacher School and learned Russian language there. Afterwards, he began to create precious works during this period. He produced many newspapers and magazines throughout his life. He wrote about fifty works such as novels, stories and dramas. He died in Ankara on July 22, 1954.

As a writer, politician and journalist he had a tendency to Socializm for a while, but the developments did not seem to be what he wanted, then he changed his way over time. The newspaper titled Tercüman, which he read in his youth, laid the foundations of his nationalist and libertarian ideas.

Ayaz İshaki, in his book Bay Uġılı (Son of the Rich Family), discusses the rich Tatar families and their viewpoints of life. The novel consists of events that occur around Kerim who is the child of an ignorant but wealthy family. The ignorance of his family, his scholar Fehri’s fraud, the fact that the old-minded people around him transform the concept of religion into a means of exploitation, and bad conditions of Tatar society are the issues discussed in the novel. Ishaki, in this novel, tried to address what should and should not be done to prevent the Tatars from disappearing.

In this study, Ishaki’s novel Bay Uġılı was discussed. The religious and nationality phenomena of the novel was examined.


**Keywords:** Ayaz Ishaki, Novel, Religion, Nation, National Identity.

## 1. Кереш

Татар әдәбиятының мөхтәрәм шәхесләреннән берсе булган язучы, нәшир һәм сәясәтче Гаяз Исхакый (1878-1954), илледән артык әсәре белән татар әдәбияты мирасын баетуда үзеннән зур өлеш кертеп калдыра. Исхакый үзе дә әсәрләреннән алтысының роман икәнлеген белдерә. Болар – “Бай угылы”, “Теләнче кызы”, “Өйгә таба”, “Мулла бабай”, “Татар кызы” һәм “Бер тоткарның саташуы” әсәрләре (Исхакый, 1991: 666-669; Исхакый, 2001: 441-445; Çağatay h.б., 1979: XXII-XXIV). Роман дип аталсалар да, бу әсәрләрнең повесть дәрәҗәсендә икәнлеген билгеләп үтәргә кирәк.

XX гасыр башында татар әдәбиятын югары ноктага ташыган Исхакый иҗаты большевистик инкыйлаптан соң да татар әдәбиятының формалашуына һәм үсешенә зур йогынты ясый. Татар халкының милли идеологиясен барлыкка китерүдә һәм аны милли азатлык өчен көрәш байрагына әйләндерүдә мөһим роль уйный (Сәхапов, 1997a: 224). XX гасыр башында Исхакый татар халкының чын әдибе, аксакалы булып күтәрелгән кеше (Гали, 2018: 14). Бу чор әдәбиятында милли фикер белән шәхес иреге төшенчәләрен үзәккә алган романтизмның аерым төрләре һәм формалары шигырьдә Габдулла Тукай һәм прозада бөек осталар белән берлектә Гаяз Исхакый әсәрләрендә чагылыш таба (Yarullina Yıldırım, 2016: 41). Ләкин Исхакыйны тулысы белән романтик та, реалист та диеп булмый. Аның үзенә генә хас өслүбе бар (Seydahmet, 1979: 154) һәм аны үз чоры язучыларыннан аерып торган үзенчәлекләрнең берсе дә – шушы.

Исхакый – үз милләте өчен янган, аның өчен борчылган, тел һәм әдәбиятны да яну-борчулары өчен корал буларак кулланган бер сәнгатьче. Аның бу үзенчәлеген бөтен әсәрләрендә дә күрергә мөмкин. Гомере буе язган барлык әсәрләрендә, шул исәптән “Бай угылы” исемле романында да язучы уртага бер фикер куярга тырыша һәм шушы фикергә нигезләнеп яза.

Исхакый – прагматист карашка ия язучы. Бу үзенчәлеге аңа гомеренең төрле чорларында төрле дөнья карашларын кабул итү һәм бу юнәлештә язу өчен җирлек әзерли, юл ача. Ул – татар халкын, татар телен һәм татар кемлеген/үзенчәлеген тормышының үзәгенә куйган һәм әлеге юлдан һич тә тайпылмый азагына кадәр көрәшкән берсе.

Үзе ышанган кыйммәтләрне тормышка ашырырга омтылган һәм үзен милләтенә хезмәткә багышлаган Исхакый өчен әдәбият бер корал булып тора. Әсәрләрендә каләмгә алган мәсьәләләрне бер-берсенә капма-каршы куеп, Исхакый конфликтларны тагын да көчәйтүгә ирешә. Аның әсәрләрендә аеруча консерватизм һәм прогрессивлык, кадимчелек һәм җәдитчелек, иске һәм яңа конфликтлары игътибарга лаек. Идеалларына ирешүдә әдәбиятны бер чара буларак күргән Исхакый, шушы аңлаешка туры китереп, авторның да тартышучы каһарманнарыннан берсе тарафында торып максатына хезмәт итүен белдерә (Kanlıdere, 2019: 178; Asrî, 1328: 49).

Гаяз Исхакый әсәрләрен бары тик әдәбият белеме күзлегеннән генә чыгып карау, аның иҗатын аңлап бетермәү булыр иде. Аның иҗаты иҗтимагый фикер, тарих, фәлсәфә, милли сәясәт, милли фикер тарихы, татар халкы тарихы кебек фәннәр яссылыгында өйрәнелергә тиеш (Сәхапов, 1997а: 25). Чөнки Исхакый, әдип булудан тыш, киңкырлылыгы белән алгы планга чыккан бер шәхес. Аны бу юлга этәргән хосус та фикер иясе, идеолог булуы һәм әдәбиятны бер алым буларак күрүендә.

Исхакыйның әдәби эшчәнлегенең беренче өлеше XX гасырның башына, ватанында яшәгән вакытка туры килә. Язучының әлеге вакыт аралыгындагы әдәби эшчәнлеген Мәгърифәтчелек чоры (1897-1904), Таңчылык дәвере (1905-1911) һәм 10 нчы еллар (Миллиятчелек) дәвере буларак карарга мөмкин. Исхакыйның тормышының һәм иҗатының икенче өлешен Мөһаҗирлек дәвере (1919-1954) тәшкил итә (Заһидуллина һ.б., 2004: 144; Ганиева, 1998: 63-78). 1917 елгы инкыйлаптан соң ватанынннан китәргә мәҗбүр булган әдип, мөһаҗирлек дәверендә дә актив эшли, көрәшен Ерак Көнчыгыштагы һәм Европадагы ватандашлары һәм төрки халыклардан булган хезмәттәшләре белән берлектә дәвам итә.

XX гасыр башыннан алып уртасына кадәр актив бер шәхес буларак танылган һәм татар әдәбиятында зур эз калдырган Исхакыйның тирәнрәк өйрәнелүе, ул яшәгән чор белән бергә шул чор татар теленең һәм әдәбиятының тулырак аңлашылуында әһәмияткә ия. Чөнки Исхакый – XX гасыр башы татар әдәбиятының иң мөһим шәхесләреннән берсе. Г.Ибраһимов һәм Г.Баттал тарафыннан 1914 елда Казанда дөнья күргән "Яңа әдәбият" исемле басмада аның күп кенә әсәрләренә урын бирелсә дә, большевистик революция һәм революциядән соңгы яңа режим тарафыннан Исхакый халык дошманы буларак игълан ителгән өчен юк ителергә, оныттырылырга тырышыла, аны телгә алу бөтенләй тыела.

Яңа татар әдәбиятына нигез салган Исхакый патша заманында эзәрлекләнгән, вакыт-вакыт төрмәгә атылган һәм сөргенгә озатылган. СССР вакытында аңа "халык дошманы" тамгасы да тагыла (Ганиева, 1998: 63). Патша хакимияте чорында Исхакый берничә тапкыр Истанбулга килә. Кайбер мәкаләләре Истанбулдагы мәҗмугаларда басылган әдип 1908 елда оешкан Төрек дәрнәги/җәмгыятенең беренче кырык әгъзасы арасында исәптә була (Kaçalin, 2000: 474). Конъюктураның да йогынтысы белән бу чорда игътибар үзәгендә булган Исхакый 1940 елда Төркиягә күченә һәм 1954 елга, ягъни вафат булганга кадәр биредә яши. Ләкин элгәре еллардагы кебек актив булып, мөмкинлекләрен тулысынча ача алмый, элеккеге кебек игътибар үзәгендә дә булмый. Бу хәл Төркия Җөмһүрияте белән СССР арасындагы мөнәсәбәтләр белән турыдан бәйле була.

Тимер пәрдә ачылганнан соң, XX гасырның икенче яртысында татар җәмәгатьчелегендә үткәнгә карата кызыксыну нигезендә эзләнүләр башланган, Совет идеологиясенә туры килмәгән өчен, тыелган әдәби әсәрләр белән бергә, язучыларның иҗаты да яңадан халыкка кайтарылган. Шуның нигезендә татар халкының үткәненә һәм

бүгенге тарихына, үткәндәге билгесезлекләренә кызыксыну тулы, тарихи чынбарлыкны чагылдырган роман һәм драмалар иҗат ителгән (Yarullina Yıldırım, 2016: 140-141).

Узган гасырның 90 нчы елларында, ягъни СССР таркалгач, Исхакый әсәрләренә булган басым юкка чыга; татарлар арасында язучының шәхесенә һәм иҗатына игътибар арта башлый. 1998-2014 еллар арасында Л.Р.Гайнанова, М.Х.Хәсәнов, Ф.М.Мусин, Ә.Н.Әхмәдуллин һәм Х.Г.Әюпов кебек танылган галимнәрдән торган коллектив Гаяз Исхакыйның барлык әсәрләрен туплаган "Гаяз Исхакый – Әсәрләр" дип аталучы күптомлык әзерләгән. Бу күптомлык Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителгән. Шулай ук Әхмәт Сәхапов, Флүн Мусин һәм Булат Гали кебек галимнәрнең Гаяз Исхакый шәхесенә һәм иҗатына багышланган хезмәтләре бар. Ләкин патша заманындагы һәм СССР вакытындагы Исхакыйга булган тискәре карашның бүген кабат торгызылырга тырышылуын да билгеләп үтәргә кирәк.

Исхакый иҗаты Төркиядә исә Алсу Камалиева һәм Ахмет Канлыдәрә кебек галимнәр тарафыннан тикшерелгән. Татарстанда һәм Төркиядә Гаяз Исхакый темасына кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре якланган.

**2. Гаяз Исхакыйның "Бай угылы" романы**

Исхакый иҗатының беренче чорын тәшкил итүче Мәгърифәтчелек дәвере (1897-1904) иҗатына караган "Бай угылы" романы 1899 елда Казанда языла һәм 1903 елда Казанда нәшер ителә. Исхакыйның тәүге әсәрләреннән берсе булган "Бай угылы" – роман буларак зәгыйфь, кимчелекле бер әсәр. Язучы моны үзе дә аңлап, 1910 елның 14 июлендә китабының икенче басмасындагы "Бай угылының икенче басылуына мөкаддимә" бүлегендә "Бай Угылының язылуында әллә никадәр кимчелекләр булса да, шул кимчелекләрне бетерү, төзәтү татар тарих әдәбиятына каршы җинаять булганга, иске хаталары, иске кимчелекләре берлән, үзгәртелмәенчә икенче бастырырга карар бирдем. Китапның унсигез-унтугыз яшьлек бер егетнең каләменнән чыкканыны онытмаенча, укучыларның бик нык тәнкыйть кылмаенча, ким якларыны кичереп, яхшы тарафларына карауларыны үтенәм" (Исхакый, 1998: 114) дип, бу хәлгә ачыклык кертә.

Исхакыйның мәгърифәтчелек чоры әсәрләреннән берсе булган "Бай угылы" романы – искелек һәм яңалык тартышмасына корылган бер әсәр. Ул традицион тормышка һәм аңлаешка тәнкыйди караш белән сугарылган.

"Бай угылы" романындагы Фатыйх бай белән Сәгыйдә абыстай, бай гына гаилә әгъзалары булуга карамастан, икесе дә иске карашлы, җаһил бер пар. Аларның Кәрим исемле малайлары туа. Уллары үсә төшкәч, аңа иптәш булсын дип, 13-14 яшьләрдә Фәхри исемле тәрбияче бер малай алалар. Карын туклыгыннан башканы таләп итмәгәнгә, тәрбия күрмәгән, урам гадәтләренә өйрәнгән бу үсмер, Фатыйх бай белән Сәгыйдә абыстай тарафыннан аеруча хуп күрелә.

Кечкенә Кәрим Сәхилә карчыктан алдарга, анасыннан тәкәбберлеккә һәм дорфалыкка өйрәнә, Фәхридән кеше мыскыллау, талау, хәйләкәрлек кебек начар гадәтләрне биш яшендә үк сеңдерә.

Мәктәп-мәдрәсә күрмәгән Фәхри, Кәримне үз кирәгенә куллана. Тәмәке тартырга өйрәтә, вакыт-вакыт эчертеп тә ала. Кәримне гаиләсеннән акча таләп итүнең төрле юлларына төшендерә.

Җәдит мәктәбенә укырга җибәрелгән Кәрим, Сәхилә карчыкның сүзе белән аннан алынып, карчыкның бер танышына сабакка җибәрелә. Карчыкның максаты – бай гаиләдән файдаланып калу. Сәхилә – иске карашлы, надан, җаһил бер кеше, аңа бары үз эше хәл ителү генә мөһим.

Кадими мәктәптә укыган, бернинди белем күрмәгән Кәрим үсә төшкәч эчке куллана башлый, хатыннар янына йөри. Өйләрендәге асрау кыз аңардан буйга узып,

өйдән куыла, ләкин моның белән генә егетнең начар гадәтләренә нокта куелмый. Бәлки игә килер дип, ата-анасы улларын өйләндерергә була. Кәримнең гаиләсен танучылар аларга кыз бирми, шуңа да ерактанрак кыз алалар. Бәдрия белән гаилә кору да 18 яшьлек Кәримгә акыл кертми. Аңа икенче хатын алырга карар кылалар. Ул гына да түгел, азып-тузып йөри торгач, Кәрим гаиләсен бөлгенлеккә төшерә, өйсез, эш урыннарсыз калырга мәҗбүр итә. Ахырда, бер фәхешханәдә бер кешенең үлеменә сәбәпче булып, үзе дә шунда алган яралардан үлеп китә.

Тол калган Бәдрия кул эшләре башкарып көн итә башлый, үз этисе дә аны ярдәменнән ташламый. Бердәнбер баласы булган улы Рифгать Бәдриягә яшәү көче бирә. Кайнатасының да Бәдриягә булган мөнәсәбәте яхшы якка үзгәрә. Рифгать үсеп буйга җитә, Кәримдә күрергә теләгән бөтен яхшы сыйфатлар бу егеттә чагылыш таба. Кайнанасы да улы Кәримнән күрмәгән игелекләрне оныгы Рифгатьтән күрә. Шулай итеп, Сәгыйдә абыстай да хатасын аңлый, аның да килене белән арасы яхшыра. Еллар үтеп, Бәдриянең әти-әнисе, кайнанасы да дөнья куялар. Улы Рифгать 18 яшендә укымышлы бер кыз белән тормыш кора һәм әнисен дә үзе янына ала. Бәдрия дә килененә карата иске кайнаналар кебек булмый, алар уртак тел табып, аңлашып яшиләр. Бәдрия оныкларын да үстерергә, тәрбияләргә ярдәм итә һәм бәхетле картлык кичереп, картаеп бакыйлыкка күчә. Рифгать тә хатыны һәм балалары белән матур тормыш сөрәләр (Исхакый, 1998: 113-153).

Исхакый бу романында үз чорының татар җәмгыятенә һәм аның надан байларына күзге тота. Җәмгыятьнең чагыштырмача югары катлавын тәшкил иткән бу төркемнең бала тәрбияләү һәм белем алу кебек мәсьәләләрдәге ялгышларын ачып салырга тырыша. Исхакыйның максаты – татар халкының иске яшәү рәвеше һәм аңа бәйле проблемаларны күрсәтеп, аларны җәдиди – яңа ысул белән хәл итү юлларын аңлатырга тырышу. Роман геройларының берсе булган Кәримнең бала чагында җәдиди бер мәктәпкә укырга бирелүе – татар халкының иске яшәү рәвеше һәм аның белән бәйле проблемаларны чишүдә юл күрсәтү ул. Ләкин романда кадими караш бу фикердән өстен чыга һәм Кәрим искечә ысулда белем ала; шуның нәтиҗәсендә чын белем алудан мәхрүм кала. Тегермәнче кызы булган Бәдрия һәм улы Рифгать образлары аркылы романда җәдиди ысул – яңача фикерләү ассызыкланып, кадими ысул тәрбиясе җимеше булган Кәрим белән аның гаиләсенең барлык кимчелекләренә карамастан, бер ана буларак Бәдриянең сабырлыгы һәм гайрәте нәтиҗәсендә тәрбияләнгән Рифгатьнең уңышлары аша җәдиди фикернең кадими фикердән өстенлеге символик формада алгы планга чыгарыла.

Исхакыйның “Бай угылы” романында ул яшәгән чорның татар җәмгыяте чагылыш таба. Әсәрдә кадими карашның, кадими ысулның тискәре якларыннан юлга чыгып, яңача яшәү, яңача фикерләү алымының уңай ягы, файдасы чагылдырылырга тырышыла.

Исхакыйның “Бай угылы” исемле бу әсәре әдәби җәһәттән бигрәк, каләмгә алынган проблемалары ягыннан игътибарга лаек. Исхакый киләчәк буынның тәрбияле, белемле булырга тиешлегенә басым ясый (Сәхапов, 1997б: 65-66). Милләтенең киләчәге өчен борчылган әдип киләчәк буынның тәрбиясе һәм мәгърифәте милләтенең киләчәген гарантияли дигән фикерне алга сөрә.

### 2.1. “Бай угылы” романында дин төшенчәсе

Антропологик яктан тулысы белән билгеләнгән бер атамасы булмаса да, сүзлектә дин “Аллаһы Тәгаләнең, гомумән, нинди дә булса югары көчләрнең чынлап та булуына, барлыгына ышану, инану белән бәйле халәт; Алла, фәрештә, төрле рухларның һ.б.ш. табигатьтән өстен көчләрнең булуына ышануга нигезләнгән карашлар, күзаллаулар системасы” (Сабитова һ.б., 2016: 176); “Тәңрегә, табигать өсте көчләргә, төрле изге әйберләргә ышануны һәм табынуны системалаштырган бер социаль институт, диянәт; бу дәрәҗәдәге ышанычларны кануннар, оешмалар, гореф-гадәтләр, символлар формасында

туплаган, урнаштырган тәртип, ышаныч нигезендә барлыкка килгән фикер бәйлелеге, ышаныч яки идеал, культ” (Akalın һ.б., 2011: 668-669) буларак ачыклана. Фрейд дин феноменын гомуми бер невроз буларак билгели. Дуркхеим исә динне социаль бердәмлекне арттырган һәм белдергән социаль иҗат буларак күрә. Диннең функциональлеге аспектына тукталган Дуркхеим динне бер җәмгыятьнең бар булуында роль уйнаган ритуаллар һәм ышанычлар җыелмасы буларак ачыклый (Temren, 1998: 306). Мәдрәсәдә укыган һәм Татар укытучылар мәктәбендә рус телендә заманча белем дә алган Исхакыйның дингә карата фикерләре Дуркхеимнекенә якын.

Исхакый, “әхлакый һәм тәрбияви күзлектән караганда, диннең яхшы якларын күрә. Халыкны якынайтуда һәм берләштерүдә диннең ролен яхшы белә. Фанатик дин әһелләренә һәм халыкны алдаучыларга каршы чыга” (Kamalieva, 2009: 54). Мәдрәсә белеме алган һәм кыска вакыт имам булып торган Исхакый дингә прагматист караашта. Милли кемлекне, татарлыкны саклауда диннең кирәк булуы фикерен алга сөрә.

“Бай угылы” романында дин төшенчәсе ике төрле буларак бирелә. Болар – искелеккә, гореф-гадәтләргә нигезләнгән традицион, ягъни артта калган дин төшенчәсе белән аңлы сыйныфка хас дин төшенчәсе. Әсәрнең башында бәби табарга җыенган Сәгыйдә бикә янына мәхәлләнең бөтен хатын-кызы җыела, аңа ярдәм итү өчен үзләренә күрә болар бер нәрсәләр эшлиләр. Вакыт-вакыт “Я шәйхем, я мәдәт; я шәйхем, я мәдәт!” диеп дога кылып торсалар да, бәби генә дөньяга аваз салмый. Имамның төшләре һәм төш юраулары да игътибарга лаек. Бәби табарга ярдәм итү өчен акушерка чакыруга башта бөтенесе бердән каршы төшсәләр дә, бала табу авырайганнан-авырая барганга, имам теләми генә “акушер китертеп бәбиләтә ала” дип ризалык белдергәннән соң, акушер килеп вазифасын башкара (Исхакый, 1998: 115-116). Романда, хәтта, кеше тормышындагы сәламәтлек кебек мөһим мәсьәләләрдә дә искелек белән яңалык арасында конфликтның барлыгы ачык бер шәкелдә күрсәтелә һәм кадими фикер турыдан-туры җиңелүгә дучар ителә.

Кәримнең тәрбиясе өчен җаваплы булган 13-14 яшьләрдәге Фәхринең диннең ни икәнлеген белмәгән, дөнья күрмәгән үзе дә бер бала гына булуы (Исхакый, 1998: 117), язучының фикерләрен укучыга ирештергән аңлатучы тарафыннан тәнкыйтьләнә.

Искелек белән яңалык арасындагы конфликтка урын бирелгән әсәрдә мәгариф темасы да ике яклы каләмгә алынган. Яңа укыту ысулына нигезләнгән мәктәпкә җибәрелгән Кәрим, гаилә дусты Сәхилә карчыкның үз мәнфәгатьләрен хәл иттертү өчен малайның ата-анасына дини басым ясау нәтиҗәсендә аннан алынып, кадими ысул белән укуын дәвам иттерә (Исхакый, 1998: 122-127). Хәлбуки Кәримнең җәдит мәктәбендә яхшы белем алып, динне дә яхшылап өйрәнү мөмкинлеге була. Яңача укыту тарафдары булган Исхакый әсәр аша милләтенә әнә шул рәвешле үгетләр биреп юл күрсәтергә тырыша.

Романда Кәрим белән Фәхринең гашыйк булган кызларны үзләренә карату өчен багучыдан ярдәм алулары, Сәхилә карчыкның да аларга бу мәсьәләдә ярдәм иткән булып, үз мәнфәгатьләрен кайгыртуы кебек үрнәкләр белән ул чор татар җәмгыятенең проблемалы тарафлары күрсәтелә (Исхакый, 1998: 131-133). Бу шәкелдә кадими тормыш рәвешенең ялгышлары фольклор алымнары аша укучыга ирештерелә.

Исхакый дингә булган иске карашның бары шәхси проблемаларны хәл итү чарасы фикеренә каршы чыгып, укучыларын да бу мәсьәләдә агартырга тырыша. “Безнең байлар үз файдалары дигәндә кешелек хакы түгел, мөселманлык хакын да ригая кыла торганнардан түгелләр иде” (Исхакый, 1998: 137) дип, байларның характерын һәм дингә булган мөнәсәбәтен чагылдыра.

Җәмгыятьнең саф һәм чиста тарафына үрнәк буларак романда Кәримнең хатыны Бәдрия бирелә. Әсәрдә ул саф күнелле халыкның дингә булган мөнәсәбәтен чагылдыра.

Ышанычлы, чиста күнелле кеше булу белән бергә, ул һәм үз гаиләсенә, һәм ире гаиләсенә карата ихтирамлы да; Кәримнең төрле начар гадәтләре булуга карамастан, алган тәрбиясе нәтиҗәсе кирәге – иренә хөрмәтле һәм һәрвакыт аның янында (Исхакый, 1998: 140-141). "Бай угылы" исемле әсәрдә гаиләдә хатын-кызның тоткан урыны һәм әһәмияте хосусы гади бер гаиләдән чыккан, ягъни тегерменче кызы булган Бәдрия образы аша чагылдырылып, нәкъ менә Бәдрия образы мисалында гаиләдә хатын-кызның урыны үзәктә булырга тиешлеге күрсәтелә.

Бәдрия мисалында романда позитив, ләкин изелгән хатын-кыз образы уртага чыгарыла. Монда хатын-кызга кол мөнәсәбәте тудырган кадими дин аңлаешын билгеләп үтәргә кирәк. Татар хатын-кызларының хөрлеге өчен тырышкан Исхакый, романы аша аларның тормыштагы хәлен чагылдырып, үз чоры укучыларына да тәкъдим итә.

Чорының дөньяга карашы һәм бай гаиләнең чикләнмәгән мөмкинлекләре нәтиҗәсендә Кәримдәге бөтен начар гадәтләргә күз йомыла килә, аның өйләнеп тә акылга утырмавында хатыны Бәдрия гаепле булып чыга. Моны сәбәп итеп, гаиләсе Кәримгә тагын бер хатын алу фикеренә килә, чөнки дин дә моңа каршы төшми. Бәдрия моны теләмәсә дә, кайнанасын бу фикереннән кире кайтарырга никадәр тырышса да, хатын-кыз буларак аның моңа каршы төшү хакы булмый (Исхакый, 1998: 144-147). Исхакый диннең ир-ат хокукларын гына яклавына, хатыннарның бу сәбәптән җәмгыятьтән читтә калуларына каршы булган фикерләрен Бәдрия мисалы аша телгә китерә һәм әсәрнең азагында аны үзен беркайчан да яратмаган, кешегә санамаган кайнанасы белән кайнатасын коткаручы каһарман дәрәҗәсенә күтәрә. Шул рәвешле, Бәдрия образы аша патриархаль гаиләгә һәм җәмгыятькә тәнкыйди күзлектән карарга кирәклеген аңлата.

Җәмгыятьнең авырткан урыннарын әсәрендә чагылдырган Исхакый, идеалларын да уртага куя. Кәримнең улы Рифгать – яхшы белем алган, диннең бөтен асылын белгән яшь егет. Моннан тыш, ул камил дәрәҗәдә русча да белә һәм укучыга үрнәк, өлге буларак тәкъдим ителә (Исхакый, 1998: 152). Рифгать үрнәге аша язучы идеалындагы егетне милләтенә танытырга, аны кабул иттерергә омтыла. Бу егетне ул югары белемле, динен яхшы белүче, дөньяда булып беткәннәрдән хәбәрдар, ана теле белән бергә русчаны да белгән, камил бер кеше буларак сурәтли.

Гомере буе динне татарларны берләштерүче һәм саклаучы бер алым буларак күрсә дә, Исхакый этноцентрик бер караш белән татарлыкны, татар кемлеген/үзенчәлеген һәрвакыт алгы планда тота (Uzun, 2021: 178). Исхакыйның бу әсәрендә диннең коллектив аңның формалашуында өлеше булуын һәм шул рәвешле милли үзенчәлекне саклауда бер алым булып торуын да билгеләп үтү кирәк.

### 2.2. "Бай угылы" романында милләт төшенчәсе

Исхакыйның фикри мәгънәдәге милләт төшенчәсе сүзлектә "Тарихи рәвештә уртак әдәби тел, этник үзенчәлекләр, территория, мәдәният, икътисад формалашып, шуның нигезендә уртак үзаң һәм җәмгыять структурасы барлыкка килереп яшәгән зур тотрыклы бергәлек буларак халык; шәхеснең әлеге берләшмә әгъзасы булуы, шушы халыкка каравы; дәүләт, ил; кешеләр, халык; бер тармакка караган, бер өлкәдә эшчәнлек алып барган кешеләр" (Сабитова һ.б., 2017: 213); "Милли үзгәлек, миллилек; милли бәйлелек" (Akalın һ.б., 2011: 1684) буларак ачыклана. Татар тарихында шактый вакытлар Ислам дине/мөселманлык милли кемлек/үзенчәлек һәм милләт атамасы белән янәшә кулланыла. 1552 елда Казан ханлыгы басып алынганнан соң, Ислам дине татарларның милли үзенчәлеген саклаучы һәм руслар белән араларындагы аерманы чагылдыручы хәленә килә. Исхакый иҗатында да дин Русия мөселманнарының милли кемлекләрен саклаучы калкан һәм яшәү чыганагы буларак чагылыш таба. Бу ягы белән "Бай угылы" әсәрендә дин төшенчәсенең дә милли кемлек/үзенчәлек һәм милләт төшенчәсен саклаучы бер алым буларак кулланылуын күрсәтергә мөмкин.

Иң гади һәм асыл мәгънәдә милли кемлек/үзенчәлек төшенчәсе, шәхесләрнең, төркемнәрнең яки җәмгыятьләрнең “Сез кем?”, “Сез кемнәрдән?” сорауларына җавап яки җаваплары буларак кабул ителә ала (Güvenç, 1993: 3). Этник үзенчәлек исә бер бар булу постулатының нәтиҗәсе булып, субъектив буларак яшәлгән һәм кабул ителгән милек булу хисе ул (Bilgin, 1995: 59). Этноцентрик бер карашка ия булган һәм фикри романнар язган Исхакыйның әсәрләрендә дин милләтне яклауда ярдәмче бер алым, бер чара буларак урын ала.

Рус хакимияте астында яшәүче татарлар тарих дәвамында этник үзенчәлекләрен дини үзенчәлекләре артына яшерергә мәҗбүр була. Алтын Урда чорының руслар тарафыннан *татарское иго (татар золымы / изүе)* буларак аталуы, татар атамасының татарларның үзләренә руслар тарафыннан билгеле бер максат белән тагылуы фикере һәм мөселман кемлеге белән өммәт кебек факторлар сәбәпле, Идел-Урал буендагы татарлар үзләрен бары тик *мөселман* буларак атау юлын сайлаганнар. Шиһабетдин Мәрҗани, русларның татар атамасына булган тискәре карашы йөзеннән үзләрен мөселман буларак танытсалар да, татарлар өчен моның җитәрсез булуын, мөселманлыклары янында бер дә *татар* этник атамасына да өстенлек бирүләрен әйтә һәм бу исемнәр (татар белән мөселман) арасында Нил белән Евфрат елгалары арасындагы ераклык кадәр зур аерма булганын телгә ала (Мәрҗани, 1989: 43-44). Мәрҗани һәм Насыйриның тәэсире белән XIX гасырның азагы – XX гасырның башында Казан язучыларының шактый бер өлеше тарафыннан әдәбиятта татар исеме кулланыла башлый (Баттал, 1996: 169). Тарихи процесста мөселман, болгар яки татар атамаларын куллану турында бәхәсләр булса да, бүгенге көндә барлык татарлар *татар* атамасын куллана.

“Бай угылы” романы – полемик рухта язылган бер әсәр. Яшь автор, әсәрнең башында, үз милләтенең авыру якларын яшерергә, аны бары матур яктан гына күрсәтергә тырышучы ялган патриотлар белән бәхәскә керә (Мусин, 1998: 19). Әсәрнең башында Исхакый бай гаилә балаларының күбесендә тәрбиянең начар булуын, я бер кешенең, яки гомуммилләтнең начар якларын яшерүнең, дәшми калуның яхшыга илтмәвен ассызыклый. Җәмгыятенең четерекле якларын, проблемаларын телгә алуны – милләтен кимсетү, рәнҗетү буларак түгел, ә, киресенчә, кара таплардан арындыруда бер юл буларак белдерә (Исхакый, 1998: 113-114). Бу юлларда халыкчы һәм милләтче Исхакыйның кемлеге чагылыш таба. Ул киләчәктә милләтенең юк булып китүеннән курка, шуның өчен янып-көя. Исхакый этноцентрик карашка ия булса да, милләтенә кагылышлы проблемаларны каләмгә алганда романтик буларак түгел, реалистик бер караштан чыгып эш итә.

Гомумән алганда, Исхакыйның “Бай угылы” әсәре, замандашларында милләтне саклау хисен уяту нияте белән язылган һәм автор тарафыннан монда милләт яшәеше өчен бик мөһим мәсьәләләрнең берсе – яшь буынны тәрбияләү темасы күтәрелгән (Мусин, 1998: 20). Милләтнең киләчәген яшьләр тәшкил иткәнгә күрә, аларның тәрбиясе һәм белеме әһәмияткә ия. Дидактик ысулда язылган бу әсәрдә язучы яшьләрне, гаиләне һәм милләтне, милли кемлекне/үзенчәлекне саклап калуга бары тик чорына туры килгән, заманча милли белем һәм тәрбия аша гына ирешергә мөмкин икәнлеген күрсәтергә тырыша. Бу карашның артында җәдиди фикер урын ала.

Исхакыйның дингә чиктән тыш дәрәҗәдә басым ясавы да, асылында, милли кемлекне/үзенчәлекне, татарлыкны саклап калу өчен. 1552 елдан бирле рус хакимиятендә яшәгән татарларның рус культурасы һәм рус сәясәте тәэсирендә юк булып китмәве, милли кемлеген/үзенчәлеген дәвам иттерә алуы өчен дини кемлекләрен/үзенчәлекләрен саклаулары һәм дәвам итүләре кирәклеген белдерә Исхакый. Әсәрдә дингә булган карашның ике тарафлы яктыртылуы шуны ачыклау максатлы бирелә.

Татарлар өчен динне берләштерүче, саклаучы бер алым буларак кабул итсә дә, Исхакый гомеренең һәр чорында диярлек этноцентрик юнәлештән эш итеп, татарлыгын,

татар кемлеген – милләтен һәрвакыт беренче урында тота (Uzun, 2020: 43). "Бай угылы" романында бары тик татар кемлеге/үзенчәлеге һәм татарларның проблемалары күтәрелә, халыкны борчыган мәсьәләләр ачыкланып, аларны җәдиди юл белән чишү мөмкинлеге аңлатыла. Исхакый әсәрләрендә милләт төшенчәсенең нигезе аның беренче әсәрләреннән берсе булган "Бай угылы" романында микро планда татарлык белән башланып, вакытлар үтү белән тагын да киңәя төшеп, "Өйгә таба" кебек әсәрләрендә төрки халыкларның бердәмлеген яклау дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә.

## 3. Йомгак

Гаяз Исхакый әдәбиятны халыкның тормышын, дөньясын үзгәртүче, аңа туры юлны күрсәтүче идеаль бер алым буларак күрә. Әсәрләрендәге үгет-нәсихәт өслүбе дә язучы фикерләренең табигый чагылышы булып тора.

Исхакыйның мәгърифәтче-җәдитчелек чорында язылган әсәрләреннән берсе булган "Бай угылы" романы, үз чорының мөһим проблемаларын күтәреп чыгып, тәрбия һәм белем мәсьәләләре төшенчәләренә киң урын бирелгәнгә күрә, нәкъ менә шушы ягы белән укучыларга сабак булырдай әсәр.

Романда милли һәм дини кемлек/үзенчәлек алгы планга куела, кешеләрнең динне үз файдаларына куллануы әсәрдә төрле образлар һәм вакыйгалар ярдәмендә укучыга тәкъдим ителә. Әсәрнең азагында милли һәм дини яктан көчле, югары белемгә ия, рус телен дә яхшы белгән, бу тел ярдәме белән дөньяга ачылган каһарманы аша язучы үз фикерләрен җиткерә һәм шул рәвешле укучыларына туры юлны күрсәтә.

Динне Русия мөселманнарын берләштерүче һәм милли үзенчәлекләрен саклаучы бер алым буларак күрсә дә, Исхакыйның милли тойгылары дингә караганда һәрвакыт беренче урында алгы планда була.

Ватанында да, мөһаҗирлектә дә, ягъни гомер буе татар милләтенең яшәеше һәм киләчәге өчен көрәшкән Исхакый, әсәрләрен дә шушы көрәштә бер алым буларак кулланган. "Бай угылы" әсәрендә дин һәм милләт төшенчәләре бу рәвешле чагылыш тапкан.

**Әдәбият исемлеге**


Akalın, Ş. H., Toparlı, R., Argunşah, M. vd. (2011). *Türkçe Sözlük*. Ankara: TDK Yayınları.

Asrî, N. (1328). *Şimalî Türk Ediplerinden Ayaz İshakî*. İstanbul: "Tanin" Matbaası.

Баттал, Г. (1996). *Казан Төркиләре*. Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [Battal, Ġ. (1996). *Qazan Törkiylerĕ*. Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Bilgin, N. (1995). *Kollektif Kimlik*. İstanbul: Sistem Yayıncılık.

Çağatay, T. (1979). *Ayaz İshakî İdilli'nin Eserleri*. (Haz. Tahir Çağatay, Ali Akış, Saadet Çağatay-İshakî, Hasan Agay). Muhammed Ayaz İshakî Hayatı ve Faaliyeti 100. Doğum Yılı Dolayısıyla. Ankara: Ayyıldız Matbaası: XXII-XXIV.

Гали, Б. (2018). *Давыл Хәбәрчесе*. Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [Ġali, B. (2018). *Dawıl Ḫeberçĕsĕ*. Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Ганиева, Р. (1998). Исхакый Иҗаты. *Мирас*, №. 5, Б. 63-78. [Ġaniyeva, R. (1998). İsḫaqıy İcatı. *Miras*, №. 5, s. 63-68.]

Güvenç, B. (1993). *Türk Kimliği – Kültür Tarihinin Kaynakları*. Ankara: Kültür Bakanlığı Yayınları.

Исхакый, Г. (2001). *Әсәрләр: 15 Томда. 3 Том* (төзүче: Лена Гайнанова). Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [İsḫaqıy, Ġ. (2001). *Eserler: 15 Tomda. 3 Tom* (tözüwçĕ: Lena Ġaynanova). Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Исхакый, Г. (1998). *Әсәрләр: 15 томда. 1 том: Повестьлар һәм Хикәяләр (1899-1908)* (төзүче: Лена Гайнанова. Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [İsḫaqıy, Ġ. (1998). *Eserler: 15 Tomda. 1 Tom: Povestlar hem Ḫikeyeler (1899-1908)* (tözüwçĕ: Lena Ġaynanova). Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Исхакый, Г. (1991). *Зиндан – Сайланма Проза һәм Сәхнә Әсәрләре* (төзүчеләр: М. Госманов, Ф. М. Миңнуллин, Ф. М. Мусин, М. С. Мәһдиев, Р. С. Мөхәммәдиев, Х. Ә. Әшрәфҗанов). Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [İsẖaqıy, Ġ. (1991). *Zindan – Saylanma Proza hem Seẖne Eserlerĕ* (tözüwçĕler: M. Ġosmanov, F. M. Miŋnullin, F. M. Musin, M. S. Mehdiyev, R. S. Möẖemmediyev, H̱. E. Eşrefcanov). Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Kaçalin, M. S. (2000). *İdilli, Muhammed Ayaz İshakî*. İslam Ansiklopedisi. İstanbul: Türkiye Diyanet Vakfı Yayınları, C. 21, s. 474-476.

Kamalieva, A. (2009). *Romantik Milliyetçi Ayaz İshakî*. Ankara: Grafiker Yayınları.

Kanlıdere, A. (2019). *Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshakî.* İstanbul: Ötüken Neşriyat.

Мәрҗани, Ш. (1989). *Мөстәфадәл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар* (тәрҗемә итүче һәм төзүче: Ә. Н. Хәйруллин). Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [Mercani, Ş. (1989). *Möstefadel-Eẖbar fi Eẖvali Qazan we Bolġar* (tercĕme itüwçĕ hem tözüwçĕ: E.N. H̱eyrullin). Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Мусин, Ф. М. (1998). *Гаяз Исхакый*. Казан: Татарстан Китап Нәшрияты. [Musin, F. M. (1998). *Ġayaz İsẖaqıy*. Qazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.]

Сабитова, И. И., А. Ф. Гайнетдинова, Ю. Ф. Борһанова h.б. (2017). *Татар Теленең Аңлатмалы Сүзлеге: III Том: К.* Казан: ТӘһСИ. [Sabitova, İ. İ., A. F. Ġaynĕtdinova, Yu. F. Borhanova h.b. (2017). *Tatar Tĕlĕnĕŋ Aŋlatmalı Süzlĕgĕ: III Tom: K.* Qazan: TEHSİ.]

Сабитова, И. И., Ф. И. Таһирова, А. М. Сәгыйтова h.б. (2016). *Татар Теленең Аңлатмалы Сүзлеге: II Том: Г-Й.* Казан: ТӘhСИ. [Sabitova, İ. İ., F. İ. Tahirova, A. M. Seġıytova h.b. (2016). *Tatar Tĕlĕnĕŋ Aŋlatmalı Süzlĕgĕ: II Tom: G-Y.* Qazan: TEHSİ.]

Сәхапов, Ә. (1997a). *Исхакый Иҗаты. Монография.* Казан: Татар "Мирас" Китап Нәшрияты. [Seẖapov, E. (1997a). *İsẖaqıy İcatı. Monografiya.* Qazan: Tatar "Miras" Kitap Neşriyatı.]

Сәхапов, Ә. (1997б). *Исхакый һәм XX Гасыр Татар Әдәбияты. Монография.* Казан: Татар "Мирас" Китап Нәшрияты. [Seẖapov, E. (1997b). *İsẖaqıy hem XX. Ġasır Tatar Edebiyatı. Monografiya*. Qazan: Tatar "Miras" Kitap Neşriyatı.]

Seydahmet, K. C. (1979). Kazan Edebiyatı ve Ayaz İshaki (Haz.) Tahir Çağatay, Ali Akış, Saadet Çağatay-İshaki, Hasan Agay. Muhammed Ayaz İshaki Hayatı ve Faaliyeti 100. Doğum Yılı Dolayısıyla. Ankara: Ayyıldız Matbaası: s. 150-157.

Temren, B. (1998). Din Antropolojisi Açısından İnanç ve Din Olgusuna İlişkin Bir Değerlendirme. *DTCF Dergisi*, C. 38, S. 1-2, s. 301-312.

Uzun, M. (2020). *Ayaz İshakî'nin "Öyge Taba" Adlı Romanı Üzerinde Dil ve Üslûp İncelemesi.* Yayımlanmamış Doktora Tezi, Kocaeli: Kocaeli Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü.

Uzun, M. (2021). "Muhammed Ayaz İshakî'nin Hayatı ve Eserleri". (Ed.) Akartürk Karahan. Türk Dünyası Dil, Kültür ve Edebiyat İncelemeleri – Türkbilim Araştırmaları Dizisi: 3. Kitap. İstanbul: Kutlu Yayınevi: 174-189.

Yarullina Yıldırım, R. (2016). *Tatar Nesri ve Romantizm Estetiği*. İstanbul: Kesit Yayınları.

Заһидуллина, Д. Ф., Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев (2004). *Татар Әдәбияты – Теория Тарих.* Казан: "Мәгариф" Нәшрияты. [Zahidullina D. F., E. M. Zakircanov, T. Ş. Ġıylecev (2004). *Tatar Edebiyatı – Teoriya Tariyẖ*. Qazan: "Meġarif Neşriyatı.

**Etik, Beyan ve Açıklamalar**

**1.** Etik Kurul izni ile ilgili;

☑ Bu çalışmanın yazar/yazarları, Etik Kurul İznine gerek olmadığını beyan etmektedir.

**2.** Bu çalışmanın yazar/yazarları, araştırma ve yayın etiği ilkelerine uyduklarını kabul etmektedir.

**3.** Bu çalışmanın yazar/yazarları kullanmış oldukları resim, şekil, fotoğraf ve benzeri belgelerin kullanımında tüm sorumlulukları kabul etmektedir.

**4.** Bu çalışmanın benzerlik raporu bulunmaktadır.